**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы**

# КАРАР

“06”август 2018ел Яңа Бүләкавылы №8/1

«Яңа Бүләк авыл җирлеге бюджеты хисап
проекты үтәлеше буенча 2018 елның
1 яртыеллыгында ачык тыңлаулар үткәрү турында».

Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатыннан, Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, «Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Советының 2018 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турындагы бюджет хисап» карары проектын тикшерүдә катнашу өчен Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы

**КАРАР БИРӘМ :**

1. Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге Советының «Тукай муниципаль районы Яңа Бүләкавыл җирлеге бюджетының 2018 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турында Отчет» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.
2. Әлеге Карарны 29 августан да сонга калмыйча Тукай муниципаль районы рәсми порталында (www. tukay.tatarstan.ru/ ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яңа Бүләк авылы җирлеге бинасы янында җиһазландырылган мәгълүмат такталарында урнаштырырга
3.Ачык тыңлауларны уздыру көнен билгеләү:
3.1.2018елның 13 август көнне, сәгать 10.00 уздыру;
3.2.Уздыру көне – 1 көн ;

3.3.Уткәрү урыны – ТР, Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге, Г.Тукай урамы, 38нче йорт (**Биклән авыл җирлеге авыл мәдәният йорты бинасы, утырышлар залы)**

3.4.Сораулар ,тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне Яңа Бүләк авылы, Г.Тукай урамы, 2а йорт, (эш көннәрендә-8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр) бирергә кирәк

3.5.Ачык тыңлауларда катнашу хокукы белән гаризаларны бирү вакыты: 2018 елның 6 августка кадәр (тел. 79-57-58.

4.Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге башкарма комитетына «Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк авыл җирлеге бюджетының 2018 елның 1 яртыеллыгында үтәлеше турында хисап» карар проекты буенча ачык тыңлауларны бирелгән вакытта әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Яңа Бүләк авыл җирлеге Башлыгы М.С.Сагетдинов